Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
"Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең гражданнар
җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге составына керүче Монай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 22 декбреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге составына керүче Монай авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылы яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, I-II төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формалары студентларыннан тыш.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
   1) җирлек территориясен төзекләндерү (җирлек территориясен зур габаритлы чүп-чардан тигезләү һәм чистарту, чүп-чар чыгару);
   2) спорт тренажерлары сатып алу;
   3) урам сәхнәсе өчен материал сатып алу.
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Монай авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru «Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Монай авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Кириллов